ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Балалар учреждениеләрендә педагогик эшчәнлек алып бару чоры балалар учреждениеләрендә педагогик эшчәнлек алып баручы затларга картлык буенча хезмәт пенсиясен вакытыннан алда билгеләү хокукы бирүче эш стажына кертелә торган вазыйфалар һәм учреждениеләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мөрәҗәгате хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Балалар учреждениеләрендә педагогик эшчәнлек алып бару чоры балалар учреждениеләрендә педагогик эшчәнлек алып баручы затларга картлык буенча хезмәт пенсиясен вакытыннан алда билгеләү хокукы бирүче эш стажына кертелә торган вазыйфалар һәм учреждениеләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгатен кабул итәргә һәм аны Россия Федерациясе Хөкүмәтенә җибәрергә.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына җибәрергә.

3. Әлеге карарны республика массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 22 феврале
№ 1864-VI ДС

**Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга**
**Балалар учреждениеләрендә педагогик эшчәнлек алып бару чоры балалар учреждениеләрендә педагогик эшчәнлек алып баручы затларга картлык буенча хезмәт пенсиясен вакытыннан алда билгеләү хокукы бирүче эш стажына кертелә торган вазыйфалар һәм учреждениеләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында**
**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате**

Хөрмәтле Михаил Владимирович!

Дәүләт тарафыннан балаларның һәрьяклап рухи, әхлакый, интеллектуаль һәм физик үсешенә, аларда патриотизм, гражданлык хисләре һәм өлкәннәргә карата хөрмәт тәрбияләүгә ярдәм итә торган шартлар тудырыла. (Россия Федерациясе Конституциясенең $67^1$ статьясындагы 4 өлеше).

Россия Федерациясе Президенты В.В. Путин күрсәтмәсе нигезендә 2022 елның сентябреннән Россиянең 45 төбәгендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда тәрбия эшләре һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек буенча директор киңәшчесе вазыйфасы кертелде, ә 2023/2024 уку елыннан мондый белгечләр илнең бөтен мәктәпләрендә, һөнәри белем бирү оешмаларында барлыкка киләчәк. Күрсәтелгән вазыйфа Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 21 февралендәге 225 номерлы карары белән расланган белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары, мәгариф оешмалары җитәкчеләре вазыйфалары номенклатурасына кертелгән.

Тәрбия эшләре һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек буенча директор киңәшчесе педагогик хезмәткәрләр категориясенә керә. Шул ук вакытта әлеге вазыйфа Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2002 елның 29 октябрендәге 781 номерлы карары белән расланган Балалар учреждениеләрендә педагогик эшчәнлек алып бару чоры Балалар учреждениеләрендә педагогик эшчәнлек алып баручы затларга картлык буенча хезмәт пенсиясен вакытыннан алда билгеләү хокукы бирүче эш стажына кертелә торган вазыйфалар һәм учреждениеләр исемлегенә (алга таба – Вазыйфалар исемлеге) кертелмәгән. Бу – балалар мәгариф оешмаларында кимендә 25 ел педагогик стаж булган очракта «Россия Федерациясендә иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә картлык буенча тиешле иминият пенсиясен алу хокукын юкка чыгара.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, Вазыйфалар исемлегенә «Тәрбияче» вазыйфасы кертелгән, әмма Татарстан Республикасының һәм Россиянең кайбер субъектларының мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының штат расписаниеләрендә «Тәрбияче» вазыйфасы белән бергә «Рус телен өйрәтү

буенча тәрбияче», «Туган телне өйрәтү буенча тәрбияче» һәм «Чит телне өйрәтү буенча тәрбияче» вазыйфалары да расланган.

«Рус телен өйрәтү буенча тәрбияче», «Туган телне өйрәтү буенча тәрбияче» һәм «Чит телне өйрәтү буенча тәрбияче» вазыйфалары Вазыйфалар исемлегендә булмау сәбәпле, Россия Социаль фонды тарафыннан әлеге вазыйфаларда эшләү чорлары вакытыннан алда пенсия белән тәэмин итү өчен кирәкле махсус иминият стажына кертелми, гәрчә тәрбияченең һәм телләр өйрәтү буенча тәрбияченең вазыйфаи бурычлары һәм функцияләре тулысынча бер үк төрле, алар, мәктәпкәчә белем бирүнең Федераль дәүләт стандарты нигезендә уку-укыту программасы үтәлешен тәэмин итеп, балаларга белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра. Әлеге проблема илнең кайбер башка субъектларындагы мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә дә хас. Вакытыннан алда иминият пенсиясенә хокук билгеләүне хәл итү өчен алар судка мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр.

Бәян ителгәнгә охшаш мәсьәлә Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Һөнәрләр, вазыйфалар һәм оешмалар (структур бүлекчәләр) тәңгәллеген билгеләү турында» 2005 елның 5 июлендәге 440 номерлы боерыгы белән, «Мәктәп төркеме тәрбиячесе», «Мәктәп бүлеге тәрбиячесе» вазыйфаларын Вазыйфалар исемлегендә каралган «Тәрбияче» вазыйфасына тәңгәлләштереп, уңай хәл ителгән.

Хөрмәтле Михаил Владимирович!

Әлеге мәсьәләләрнең әһәмиятле булуын исәпкә алып, тәрбия эшләре һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек буенча директор киңәшчесе вазыйфасын Вазыйфалар исемлегенә кертергә тәкъдим итәбез, бу – күрсәтелгән категориядәге хезмәткәрләргә вакытыннан алда пенсия алу хокукын бирәчәк.

Шулай ук, педагогик хезмәткәрләрнең пенсия белән тәэмин итүгә хокукын гамәлгә ашыру максатларында, «Рус телен өйрәтү буенча тәрбияче», «Туган телне өйрәтү буенча тәрбияче» һәм «Чит телләрне өйрәтү буенча тәрбияче» вазыйфаларының «Тәрбияче» вазыйфасына тәңгәллеген билгеләү турындагы мәсьәләне федераль дәрәҗәдә тулысынча хәл итүне сорыйбыз. Әлеге адым, балаларга кече яшьтән үк туган телне өйрәтеп, илебезнең тел күптөрлелеген саклап калырга һәм үстерергә ярдәм итәр иде.

---